| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ НОВОМАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА ЯҢА МАҖЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

2019 ел, «15» ноябрь

№ 1

# КАРАР

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 15 ноябрендә Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында гражданнар җыены узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

- Юлларны каплау (ташу, бут ташы салу, ком вак - таш катнашмасы сибү, килешү буенча эш өчен түләү).

- Зиратта каты көнкүреш калдыклары контейнерлары сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 40 кеше, җыенда катнашучылар саны 32 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 32 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: Татарстан Республикасы Минзәл муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге территориясендә яшәү урын буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Вата сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, Бөек Ватан сугышынд катнашучыларның тол хатыннары, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә килешәсезме?; халык сан җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санынннан 30 проценттан да артмый торган һә алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерү белән бәйле.:

- Юлларны каплау (ташу, бут ташы салу, ком вак - таш катнашмасы сибү, килешү буенча эш өчен түләү), зиратка юл төзү.

- Зиратка каты көнкүреш калдыклары контейнерлары сатып алу - кабул ителде

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Мажын авыл җирлеге Советын мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматене рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Ян Мажын авыл җирлегенең муниципаль норматив хокукый актлары регистрына керт өчен җибәрергә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе: ___________